КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 сентябрь г.Казань № 724

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 19 апрель, 312 нче карары белән расланган Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 19 апрель, 312 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 март, 142 нче, 2023 ел, 29 декабрь, 1725 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктта:

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацта «һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

16 пунктта «һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин